Республика Татарстан

**СОВЕТ ПЕТРОВСКО-ЗАВОДСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ САРМАНОВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул. Поперечнаяя, д.2А, с.Петровский Завод, 423364
Телефон: 4-41-22

Татарстан Республикасы

**САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ПЕТРОВСКИЙ ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

Поперечная урамы, йорт 2А, Петровск Завод авылы 423364
Телефон: 4-41-22

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**20 сентябрь 2019 ел** **с. Петровский Завод** **№14**

## Җирле референдум үткәрү инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елнын 12 июнендэге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, “Россия Федерациясендэ җирле үзидарә оештырунынгомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октяберндәге 131-ФЗ номерла Федераль законның 22, 56 статьясылары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пункты, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Петровский Завод авыл җирлеге территориясендә җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

"I группа инвалидлар, 80 яшьтэн өлкәннәр, көндезге бүлекләрдә укучы студентлардан кала, Петровский Завод авыл җирлегендә теркәлгән 18 яше тулган һәр гражданга 2020 елда үзара салымны 200 сум кертергә һәм шул акчаларны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итщргщ тотарга Сез ризамы:

-Петровский Завод, Алан авылларында Сабантуй, Өлкәннәр көне, 9 Май үткәрү өчен бүләкләр сатып алу;

-Димитрлау, Петровкий Завод, Кук-Тау, Мостафин, Алан авылларында урам утларын ремонтлау һәм карап тоту (урам утлары лампаларын сатып алу һәм алыштыру);

-Мостафин авылы зираты өчен инвентарь, шлагбаум ясау өчен материаллар, триммер сатып алу;

- Димитарлау, Петровкий Завод, Кук-Тау, Мостафин, Алан авыллары урамнарының исемнәре язылган күрсәткечләр сатып алу;

-Беларус-82,1 тракторын карап тоту (машина йөртүчегә хезмәт хакы, запас частьләр, ягулык-майлау материаллары сатып алу);
- Петровский Завод авылын төзекләндерү буенча эшчеләргә хезмәт күрсәтүгә түләү;
- Петровкий Завод авылының Аркылы урамына вак таш җәю (килешү буенча эш өчен түләү), зиратка юл салу;
- Петровкий Завод, Димитарлау авылларында агач кисү;
- Петровкий Завод авылында, Заречная, Пушкин урамарында дренаж торбаүткәргечләр урнаштыру (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Алан авылында обелиск ясау һәм урнаштыру;

2. Әлеге карар мәгълүмат стендларына һәм авыл җирлегенең рәсми сайтына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерелергә тиеш.

Петровский Завод авыл җирлеге
Советы рәисе: А.Б. Хөснетдинов